Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт
авыл җирлеге башкарма комитеты
423066 ЯңаКармәт авылы
Муса Җәлил урамы,15а нче йорт
тел. 4-92-33 факс

Муса Җәлил урамы, 15а нче йорт
Яңа Кармәт авылы , 4203066

Исполнительный комитет
Новокиреметского сельского поселения
Аксубаевского муниципального района
42306 с.Новая Киреметь
улица Мусы Джалиля, д.15а
тел. 4-92-33 факс
ул. Мусы Джалиля, д 15а,
с.Новая Киреметь, 423066

Тел. (8-84344-4-92-33) ОГРН 1021605359709,
ОКПО 04311599, ИНН/КПП 1603001197/160301001
E-mail: *Nkir.Aks@tatar.ru*

КАРАР

**№ 10** **2021 елның 2 ноябере**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Башкарма комитетының «адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 25 декабрендәге 38 номерлы карарының 4 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында (Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитетының 03.08.20021 ел, №6, 27.09.20021 ел, №9 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән )**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон нигезендәТатарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 05.08.2021 №5 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5. пунктының 2-10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып бару һәм федераль мәгълүмати адресцы системаны эксплуатацияләүгә бәйле кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат системасы турында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 28.12.2013 ел, № 443-ФЗ Федераль закон, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 19.11.2014ел, №1221 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын игезендә төгәл яраштырып кулланыла.»;

1.2. 1.5. пунктының 11-17 абзацларын 3-9 абзацлар дип димәк санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында. «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләрен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.4. пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе тарафыннан» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитетының «адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 29.09.20021 ел, № 7 карарына үзгәрешләр кертү хакында " турында карары гамәлдән чыгарырга.

3.Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә; шулай УК Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә (http://Aksubaevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубаймуниципаль районы
Яңа Кармәт авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.Р.Шакиров